ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

_______27.02.2019___________ **г.Чистополь** **№ _______103_________**

2019 елга граждannар кеременең
һәм мөлкәт бәясенең салым
салынырга тиешле чик
күрсәткечен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 91.3 нче маддәсенә таянып, Татарстан Республикасының 16. 03. 2015 елгы “ Социаль файдаланудагы торак фондның торак биналарын найм килешүләре буенча гражданнарга бирелгән торак биналарга аларның хокукларын тормышка ашыру турында”гы 13 нче ТР законына һәм күрсәтелгән закон кушымтасында бәян ителгән гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган керемнең һәм гаиләнең һәр әгъзасыныкы яки ялгыз яшәүче гражданинныкы булган мөлкәт бәясенең салым салынырга тиешле максималь күләмен билгеләү методикасы нигезендә, Россия Федерациясенең Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 19 декабрендә кабул ителгән “2019 елның 1кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында”гы 822/пр Боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен чик күрсәткечләрен расларга:

1.1 гаилә әгъзалары ( ялгыз яшәүче гражданин) милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик күрсәткече:

1.1.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен - 1 523 610 сум;
1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 1 939 140 сум;
1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен - 2 493 180 сум;
1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 324 240 сум;
1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен - 4 155 300 сум;
1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 4 986 360 сум;
1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен - 5 817 420сум;

1.2 гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача тулай керемнең максималь күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен - 16 572,51 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 10546, 14 сум;
1.2.3. өч кешедән һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен - 9039,55 сум;

2. Чистай муниципаль районы башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә социаль файдаланудагы торак фондның торак биналарын найм килешүләре буенча торак бирүгә мохтаҗ булган гражданнар дип таныганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2нче пунктчаларында күрсәтелгән күрсәткечләрдән файдаланырга.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol. tatarstan. ru. ) урнаштыруны тәэмин итәргә. 4.Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов